# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2014 елның 27 октябре 25№

2014 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге территориясендә коррупциягә каршы комплекслы программа чараларын тормышка ашыру планын раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2006 елның 4 маендагы «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 34-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

2014 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге территориясендә коррупциягә каршы комплекслы программа чараларын тормышка ашыру планын (1 нче кушымта) расларга.

2. Чараларны гамәлгә ашыру планында каралган чаралар үтәлешен тикшереп тору өчен түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1. Нотфуллина Ф.З. - Юхмачы авыл җирлеге башлыгы;
2. Чулков П.А. - Юхмачы авыл җирлеге депутаты;
3. Колоколова Н.В. - Юхмачы авыл җирлеге депутаты.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлеге башлыгы: Р.А.Сәлахов

Әлки муниципаль районы Юхмачы
авыл җирлеге Советының
2014.27.10,25№ карарына кушымта

**2014 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге территориясендә коррупциягә каршы комплекслы программа чараларын тормышка ашыру планы**

| № т/б | Чаралар | Җаваплы | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| **1. Коррупциягә каршы корәшкә юнәлдерелгән хокукый һәм оештыру чараларын тәэмин итү** | | | |
| 1.1. | Коррупциягә каршы көрәш буенча муниципаль хокукый актлар проектларын эшләү | 2014 ел | җирлек башлыгы, башкарма комитет сәркатибы |
| 1.2. | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең, муниципаль контроль функцияләрен гамәлгә ашыруның административ регламентларын законнар нигезенә китерү | 2014 ел | җирлек башлыгы, башкарма комитет сәркатибы |
| 1.3 | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатына мониторинг ясау, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту буенча тәкъдимнәр эшләү | 2014 ел | җирлек башлыгы |
| 1.4 | Муниципаль контроль функцияләрен үтәүнец административ регламентларын куллануга мониторинг үткәрү | 2014 ел | җирлек башлыгы |
| 1.5 | Коррупция факторларын ачыклау максатында муниципаль хезмәтләр алучылар арасында сораштыру (анкеталаштыру) оештыру һәм үткәрү һәм аларны алга таба бетерү | 4 квартал 2014ел. | җирлек башлыгы, башкарма комитет сәркатибы |
| **2. Муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәүне тикшереп тору механизмын камилләштерү** | | | |
| 2.1. | Муниципаль хезмәткәрләрне керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне үз вакытында тапшыруны тәэмин итү | 2014елның 30 апреленә кадәр. | җирлек башлыгы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.2 | Җирле үзидарә органнарында коррупция фактлары турында гражданнарның шикаятьләренә һәм мөрәҗәгатьләренә анализ ясау һәм күрсәтелгән фактларны тикшерүне оештыру | квартал саен | Башкарма комитет сәркатибы |
| 2.3. | Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда җирле бюджетның бюджет чыгымнары нәтиҗәлелегенә анализ ясау | квартал саен | авыл җирлеге башлыгы,<br>баш хисапчы |
| 2.4. | Муниципаль мөлкәтне арендага тапшыруга анализ | ярты елга бер тапкыр | авыл җирлеге башлыгы |
| 2.3. | Авыл җирлеге территориясендә күчемсез мөлкәттән файдалануны тикшереп тору | ярты елга бер тапкыр | авыл җирлеге башлыгы |
| 2.5. | Коррупция фактларын кисәтү һәм тошереп калдыру, административ киртәләрне киметү буенча килештерелгән чаралар эшләү максатында җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары һәм эшмәкәрләр катнашында утырышлар оештыру һәм үткәрү (килешү буенча) | ярты елга бер тапкыр | авыл җирлеге башлыгы |